ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2021 г. Заинск № 55

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше нәтиҗәләре һәм республика финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча (04.01.2021 № ПР-3) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясе беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары (ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2014 ел № 157, 10.02.2014 ел № 253, 12.10.2015 ел № 1792, 26.04.2016 ел № 777, 21.03.2017 ел № 466, 24.01.2018 ел № 73, 04.09.2019 ел 472 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация

түләүләре бирү тәртибенең 2 бүлегенең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле “к” пунктчасы белән тулыландырырга:

«k) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р. Печина
3-27-42